КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 21 май г.Казань № 416

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 313 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 313 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 26 сентябрь, 464 нче; 2005 ел, 1 ноябрь, 517 нче; 2005 ел, 29 декабрь, 661 нче; 2006 ел, 1 март, 87 нче; 2006 ел, 21 апрель, 198 нче; 2006 ел, 9 июнь, 293 нче; 2007 ел, 18 май, 196 нчы; 2008 ел, 15 июль, 509 нчы; 2009 ел, 5 июнь, 360 нчы; 2009 ел, 17 август, 551 нче; 2010 ел, 8 июнь, 440 нчы; 2010 ел, 14 октябрь, 808 нче; 2010 ел, 2 декабрь, 976 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 7 октябрь, 838 нче; 2011 ел, 15 ноябрь, 935 нче; 2012 ел, 22 август, 726 нчы; 2012 ел, 24 декабрь, 1139 нчы; 2013 ел, 18 февраль, 110 нчы; 2013 ел, 7 март, 152 нче; 2013 ел, 27 апрель, 286 нчы; 2013 ел, 10 август, 558 нче; 2014 ел, 21 апрель, 261 нче; 2015 ел, 1 июнь, 397 нче; 2016 ел, 10 октябрь, 733 нче; 2016 ел, 13 декабрь, 925 нче; 2017 ел, 6 март, 127 нче; 2017 ел, 26 май, 309 нчы; 2017 ел, 14 ноябрь, 867 нче; 2018 ел, 4 июль, 545 нче; 2018 ел, 24 июль, 586 нчы; 2018 ел, 10 декабрь, 1107 нче; 2018 ел, 14 декабрь, 1135 нче; 2019 ел, 16 апрель, 301 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3 нче пунктның 3.3.3 нче пунктчасында:

унынчы абзац үз көчен югалткан дип санарга;

ундүртенче абзацка «, әгәр дә төзелеш, реконструкция эшләре ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлек (муниципаль район, шәһәр округы) территорияләрендә гамәлгә ашырылган булса, төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, шулай ук шәхси автомобиль юлларыннан тыш)» сүзләрен өстәргә;

унбишенче абзацка «, әгәр дә төзелеш, реконструкция эшләре ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлек (муниципаль район, шәһәр округы) территорияләрендә гамәлгә ашырылган булса, төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, шулай ук шәхси автомобиль юлларыннан тыш)» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин